## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"17" ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2021 елның 17 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу, куаклар һәм агачлар кисү);
2) "Маһитап" чишмәсе территориясен төзекләндерү өчен утырту материалы һәм чәчәк үстерү өчен савытлар сатып алу;
3) Кышлау авылында кое өчен койма урнаштыру, материаллар сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
4) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
5) Кышлау авылында янгынга каршы җир асты су резервуары алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
6) Кышлау авылында ритуаль инветарьны саклау өчен корылма төзү, материаллар сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 268 (ике йөз алтмыш сигез) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 163 (йөз алтмыш өч) кеше, бу 60,82 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 163 (йөз алтмыш өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2022 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кышлау авылы территориясен чистарту (үлән чабу, куаклар һәм агачлар кисү);
2) "Маһитап" чишмәсе территориясен төзекләндерү өчен утырту материалы һәм чәчәк үстерү өчен савытлар сатып алу;
3) Кышлау авылында кое өчен койма урнаштыру, материаллар сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
4) урам утларына хезмәт күрсәтү өчен түләү;
5) Кышлау авылында янгынга каршы җир асты су резервуары алу һәм урнаштыру (килешү буенча хезмәт хакы түләү);
6) Кышлау авылында ритуаль инветарьны саклау өчен корылма төзү, материаллар сатып алу (килешү буенча хезмәт хакы түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Кашшапов А.Х.